# ЭКОЯЗ - 2017нең символы
# Аккош булачак

Быел татарстанлыларны чисталыкка өндәү аккош үрнәгендә булачак. Республиканың экология һәм табигый байлыклар министрлыгы ЭКОяз - 2017 нең символы итеп суда йөзүче матур кошны билгеләргә уйлый.




Кулланылган әдәбият:
1. «Балачак аланы». Хрестоматия. Казан РИЦ нәшрияты 2011.
2. Интернет рисурслар.
3.”Мир вокруг нас: птицы России”М:”Оникс 21 век” 2002.
4.”Птицы в городе» Михайлов К.Е.//Биология .№2 2000.
5.ТР Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты.
6.Татар энциклопедиясе. Казан, 2008.


**Сез шуны һәрчак истә тотыгыз:**
**аккошлар - сак кошлар.**
**Алар саф һава, көмештәй саф су,**
**тынычлыкны яраталар.**



Хөрмәтле ата-аналар, тәрбиячеләр, балалар!

Туган шәһәребезгә мәхәббәт, шушы шәһәрдә яшәвебез белән горурлану хисләре тәрбияләүдә балаларны шәһәребез янындагы “Аккош күле” белән таныштыруның әһәмияте зур Туган ягыбызның матур табигатен аккошлар бик ярата. Алар иң матур, иң җимле урыннарны гына сайлыйлар, шулай булмаса һәр ел саен күпме юллар үтеп кайтырлар иде микән? Бөек рус педагогы К.Д.Ушинский фикеренчә балаларны туган җир тарихы, географиясе һәм табигате белән таныштыру милли горурлык хисләре тәрбияли.

Аккошлар парлашып яши. Алар – чисталык, мәхәббәт һәм тугрылык символы булып торалар. Ул – бакча һәм паркларга, сулыкларга ямь бирүче. Аккош – табигатьнең йөзек кашы. Аккош тавышсыз һәм җиңел йөзә.

Аның судагы һәр хәрәкәте кабатланмас нәфислек тудыра. Аккошларга багышлап шигырьләр, җырлар иҗат ителгән. Ул иң зур һәм иң көчле кошларның берсе. Аккошлар сайрамый лар, кайвакыт кыйгакларга яки ысылдарга гына мөмкин.

Ә Кызыл китап һәм тыюлыкларга карата игътибар җитәрлек дәрәҗәдә юнәлтеләме соң?! Һәм башка шундый сораулар безне бик борчый. Балалар боларны, әлбәттә, белергә тиеш, чөнки безнең киләчәгебез, халкыбызның алдагы көне, язмышы табигатьнең ни дәрәҗәдә сакланып калуы белән тыгыз бәйләнгән.

Гафурова Н.В.





**Аккош**

**Габдулла Тукай**

Туганлының тып-тын күлендә
Кояш ята көлеп төбендә,
Күл өстенә төшкән күк өстендә
Аккош йөзеп бара тын гына.
Муеннары айдай уелган,
Агып төшкән судай коелган,
Коелып-чәчелеп киткән шул су
Канатлары өскә кыелган.

Безнең Түбән Кама районында “Аккош күле” бар. Анда аккошлар күпләп үрчесен өчен бөтен шартлар тудырылган. Түбән Кама районының Аккош күлендә Татарстанның Кызыл китабына кертелгән 20 аккош яши. Аккошларны даими су биеклеге һәм азык төрлелеге (суүсемнәрдән алып бакага кадәр) җәлеп итә. Аккош күле экология полициясе күзәтүендә, биредә ау да тыелган.







**Ике аккош**

Бәхти Гайсин көе Әхсән Баян сүзләре

Һаваларда оча ике аккош,
Каурыйлары җиргә коела.
Янып сөйсәң, күңел канатлана,
Мәңге талмас кебек тоела.
Һаваларда очкан ике аккош
Аерылмыйча яшәр гел бергә.
Без очарбыз бәхет киңлегендә
Синең белән икәү гомергә.
Һаваларда очкан ике аккош
Талгын гына канат кагына.
Әллә нигә бергә чакларда да
Күңелем һаман сине сагына.
Һаваларда оча ике аккош,
Еракларга китә моңнары.
Киләчәккә аккош юлы булып
Китсен безнең яшьлек еллары.

**Аккош ялгыз яшәмәс.**

**Баланы биеткәндә**

Әй чулпысы, чулпысы,
Бигрәк матур тәңкәсе.
Аккош микән, былбыл микән,
Моны тапкан әнкәсе.



**Ялгыз аккош** *Рябина Хат*

Яр буенда ялгыз аккош
Бәргәләнеп, әрнеп кычкыра
Ярдан-ярга шулай бәргәләнеп
Күкләрдән үз парын чакыра.
Әллә инде, берәр аучы
Аны шулай ялгыз иттеме
Әллә корган балыкчы ятьмәсе,
Аккош башларына җиттеме?
Нигә ялгыз, аккош бүген,
Ник берүзе күлләрдә?
Ул бит ялгыз оча алмый,
Матур зәңгәр күкләрдә.

**Рәсемне буя**





**Аккошла́рның** 6 төре билгеле: Татарстан Республикасында 2 төре бар. Ике төре дә Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән:

**1.Ысылдавык аккош. Лебедь - шипун.**

**2.Сары борынлы аккош. Лебедь – кликун.**



**Ысылдавык аккош** - оя ясаучы аз санлы күчмә төр, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларының су яны һәм су асты үләннәре күпләп үскән култыкларда, Сукыр Кадыш һәм Кайбыч балык үрчетү хуҗалыгы буаларында апрельдән октябрьгә кадәр яши.



**Ысылдавык аккошның оясы**

**1.Ысылдавык аккош.**

***А***ккошлар арасында иң зурысы. Авырлыгы 20-22 килограммга кадәр җитәргә мөмкин. Гәүдә озынлыгы 160 см. Канатларын җәйгәндә бер канат очыннан икенче канат очына кадәр 200 см. Канатының озынлыгы җыйган халәттә – 62 см. Каурыйлары ап-ак төстә. Томшык төбендә кара төстәге йөгәне бар. Муены озын, «S» формасында. Томшыгын аккош аска каратып тота.



Ана кош 5-8 йомырка сала һәм алар өстендә 36 көн утыра.



**- ысылдавык аккошның дөньяда иң таралган яшәү урыннары**

**- ысылдавык аккошның Россиядә иң таралган яшәү урыннары**





**Ысылдавык аккош бәбкәләре белән**

**Нурфия Гафурова**

Табигатьнең һәрбер матурлыгы
Сихәт өсти безнең күңелгә.
Су өстендә йөзгән парлы аккош
Илһам бирә гомер-гомергә.
Һәркем шулай җирдә аккошлар күк
Парлы-парлы булып яшәсен.
Җир-суларның чисталыгын саклыйк!
Килә сезгә шулай дәшәсем.



Аккош азыкны сай сулык төбеннән чумып таба. Кысласыманнар, моллюсклар, вак балыклар, үсемлекләр белән туклана.









**Аккош нәрсә белән туклана? Рәсемнәрен яса.**



**Кара аккош (черный лебедь)**

Австралиядә яши  Иң озын муенлы. Каурыйлары – кара, томшыгы – кызыл, күзе – кызгылтсары.
Гәүдә озынлыгы – 1 – 1,5 метр.
Житлеккән кошның гәүдәсе авырлыгы – 4-9 кг.
Гомер озынлыгы – 10 ел.

Сай сулыкларда яши. Суүсемнәр белән туклана, ләкин кукуруза һәм бодайдан да баш тартмый. Йомыркалары яшькелт төстә. Бәбкәләрен ата һәм ана аккош бергәләп ашата, 5 айдан аларны очарга өйрәтәләр.



**Кара аккош ояда**





**кара аккошның дөньяда иң таралган яшәү урыннары**

**Табышмакның жавабын тап.**

Күктә оча, суда йөзә,
Муены озын, горур кош.
Кара да була ул, ак та
Исеме аның      ( аккош).



**Ребусны чиш. Монда нинди сүз яшерелгән? Рәсемен ясa.**





## 2.Сары борынлы аккош.



**Кыйгаклаучы сары борынлы аккош**

Гомерлеккә гаилә коралар. Әгәр дә пары үлсә, аккош ялгызы гына парсыз яши.

Авырлыгы – 12 кг, гәүдә озынлыгы – 1,5 метр. Канатын җәйсә, бер канат очыннан икенче канат очына кадәр ераклык 2,6 метрны тәшкил итә. Томшыгы лимон төсендә, томшык очы кара төстә.

Яшь кошларның томшыклары алсу төстә, очы кара. Очканда каты кычкыра, тавышы яңгыравыклы. Йөзгәндә алар муеннарын вертикаль рәвештә тигез итеп тота. Судан очып киткәндә, озак кына суда тизлек җыя, тәпиләре белән суны бәргәли, әкрен генә күтәрелә. Җирдә йөрергә яратмый. Кыйгаклаучы аккош бик сак кош, шуңа күрә ул ярдан ерактарак йөзәргә тырыша. Канатлары бик көчле.



Кыйгаклаучы сары борынлы аккошның яшәү **(оялау) урыннары**

### Язгы балкыш.

**Айдар Җамалиев**

Язын күлләрдә
Искиткеч балкыш.
Җылы яклардан
Кайткан бит аккош.
Ул сайрамый да,
Тик йөзә бирә.
Шулчак күңелгә
Нәфислек керә.
Көчле булса да,
Мохтаҗ яклауга
Их, аккошларны
Ничек сакларга?



**Шаулаучы (быргычы) аккош (Лебедь-трубач)**





**Шаулаучы (быргычы) аккошояда**



**Шаулаучы (быргычы) аккошның бәбкәләре**



**Кече (тундра) аккошының бәбкәсе**



**Аккош сере**

**Ришат Тухватуллин**

Һаваларда ялгыз аккош,
Пары кайларда икән?
Кыйгак- кыйгак тавышлары,
Әллә адашты микән?

Ялгыз аккош парсыз калса
Түзми диләр сагышка.
Түзә икән, яши шулай
Сабыр итеп язмышка.

Аккош булсам югарыга,
Биеккә очар идем,
Аккош серен һәрбер телдә,
Кабатлап узар идем.

**Кече (тундра) аккошының яшәү ( оялау) урыннары**





**Карамуенлы аккош (черношейный лебедь)**

Көньяк Америкада яши.
Бразилиядә кышлый.
Башы һәм муены кара, ә гәүдәсе ак төстә. Томшыгында кызыл катлам (нарост) бар.
Авырлыгы – 6,5 кг, гәүдә озынлыгы – 132 см.
Суүсемнәр, вак балыклар, уылдык белән туклана. Тиз оча (65 км/сәг)
Табигатьтә ун ел яши.

**Карамуенлы аккошның яшәү (оялау) урыннары**





Карамуенлы аккош бәбкәсе белән



**Америка аккошы (Американский лебедь).**

Ата кош тугрылыклы һәм, әнкә кош йомыркада утырганда, әнкә кошны бик нык саклый.

Башта Төньяк Американың тундраларында очрый иде. Хәзер аны күрүе авыр. Кызыл китапка кертелгән. Бик сирәк Чукотка янындагы утрауларда очратырга мөмкин.

Гәүдә озынлыгы -146 см.

Авырлыгы – 10 килограммга җитә.

Тышкы кыяфәте кыйгаклаучы аккошка охшаган, муены кыскарак.

Томшыгының очы кара, түбә ачык-сары төстә.

Сулыклар кырыена оя кора.



**Америка аккошының яшәү (оялау) урыннары**



**Америка аккошы**

## Аккошлар турында мәкальләр.

Аккош аягына су йокмас.
Аккош очар күл күреп, былбыл очар гөл күреп.
Аккош һәр күлгә төшмәс.





**Кече аккош (малый лебедь) (кыйгаклаучы аккошның кечкенә күчермәсе).**

**Аны тагын тундра аккошы дип тә атыйлар.**

Аккошлар арасында иң кечкенәсе. Россиядә тундрада безнең илнең Европа һәм Азия өлешләрендә яши. Тышкы кыяфәте белән кыйгаклаучы аккошка охшаган.

Авырлыгы - 5-6 килограмм.

Канатының озынлыгы – 55 см, ә гәүдә озынлыгы - 128 см.

Яшь тундра аккошы үсеп җиткән өлкән аккошлардан төсе белән аерылып тора: түше ачык ак төстә, ә аркасы соргылт.



**Кече аккош ояда**

Яз көне җылы яклардан кайткач, аккош оясын кеше керә алмаслык куе камышлар арасына ясый.

Ана кош 3—5 күкәй сала. Күкәйләр өстендә ана кош утыра, ата кош аның янәшәсендә йөри.

**Кече аккошның бәбкәләре ояда**

Нәни кошчыклар, кипшенүгә, эти-әниләренә иярә алалар.



## Һава торышы ничек булачагын сынау

Аккош иртә килсә, яз начар булыр, озак торыр.